ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МАКУЛОВСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮГАРЫ ОСЛАН
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ
МАКЫЛ АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

26.03.2016 с. Русское Макулово 22

Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Макыл авыл җирлеге торак пунктларын санитар-экологик чистарту икеайлыгы үткәрү турында

Югары Ослан муниципаль районының Макыл авыл җирлеге торак пунктларын төзекләндерү һәм санитар чистарту эшләрен оештыру һәм халыкның экологик иминлегенә җавап бирә торган хәлгә китерү, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 елның 21 мартындагы 452-р номерлы боерыгын үтәү өчен Югары Ослан муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесенең 2016 елның 23 мартындагы 302 нче номерлы карарын үтәү өчен.

КАРАР БИРӘМ:

1. 2016 елның 1 апреленнән 31 маена кадәр Макыл авыл җирлегенең торак пунктлары территорияләрен төзекләндерү һәм санитар-экологик чистарту икеайлыгын игълан итәргә (алга таба - ике айлык).
2. 2016елга Макыл авыл җирлеген төзекләндерү комитеты составын расларга (1 нче кушымта)
3. 2016 елның 1 апреленнән 31 маена кадәрге чорда Макыл авыл җирлеге территориясендә төзекләндерү чаралары планын расларга. (2-нче кушымта).
4. Макыл авыл җирлеге территориясендә урнашкан предприятие, оешма һәм учреждениеләр җитәкчеләренә, милек рәвешләренә бәйсез рәвештә, үзләренең якын территорияләрен санитар чистарту эшен оештырырга, каты көнкүреш калдыкларын полигонга һәм чүплекләргә чыгару өчен йөк автотранспорты бүлеп бирергә тәкъдим итәргә. Урыннарда агач һәм куаклар утырту, биналарның фасадларын, балалар мәйданчыкларын ремонтлау эшләрен оештырырга.
5. Авыл җирлеге территориясендә күчемсез милеккә ия булган гражданнарга үз йорт яны территорияләрен санитар чистарту буенча эш үткәрүне тәкъдим итәргә.

6. Әлеге карарны Макыл авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында игълан итәргә.
7. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Макыл авыл җирлеге башкарма комитеты җитәкчесе: Л.Р.Цветкова

Югары Ослан муниципаль
районының Макыл авыл
җирлеге башкарма комитеты
җитәкчесенең
2016 ел 26 март № 22
карарына
1 кушымта

Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Макыл авыл җирлегенең торак пунктларын санитария чистарту чаралары планы

| № т/б | Чараның атамасы | Үткәрү датасы | Башкаручылар |
|---|---|---|---|
| 1 | Авыл җирлегенең торак пунктлары территориясендә урнашкан чүп-чар өемнәрен барлау һәм бетерү эшләрен башкару | 15.04.2016 ел 31.05.2016 ел. | Башкарма комитет җитәкчесе, оешма, предприятие җитәкчеләре. |
| 2 | Авыл җирлеге территориясендә торак пунктлар эчендәге баганаларны буяу | 25.04.2016 ел 30.04.2016 ел | Башкарма комитет җитәкчесе, оешма, предприятие җитәкчеләре. |
| 3 | Авыл җирлеге территориясендә урнашкан учреждениеләрнең, предприятиеләрнең фасадларын ремонтлау | 15.04.2016 ел 30.04.2016 ел | Учреждениеләр, оешмалар, предприятиеләр җитәкчеләре. |
| 4 | Йортларның фасадларын ремонтлау | 15.04.2016 ел 05.05.2016 ел. | Авыл җирлеге территориясендә торак урыннар милекчеләре, яллаучылар. |
| 5 | Авыл җирлеге территориясендә урнашкан зиратларны төзекләндерү (коймаларны ремонтлау, коймаларны буяу, чүп-чарны чыгару) | 01.05.2016 ел 31.05.2016 ел | Башкарма комитет җитәкчесе, оешма, предприятие җитәкчеләре. |
| 6 | Чишмәләрне авыл территориясендә һәм авыл җирлегендә төзекләндерү | 01.05.2016 ел 31.05.2016 ел. | Башкарма комитет җитәкчесе, оешма, предприятие җитәкчеләре. |
| 7 | Авыл җирлегенең торак пунктларында яшел үсентеләр утырту. | 01.05.2016 ел 15.05.2016 ел | Башкарма комитет җитәкчесе, оешма, предприятие җитәкчеләре. |
| 8 | Авыл җирлегенең торак пунктлары эчендәге юлларны ремонтлау (җылыту, вак таш | 01.05.2016 ел. 31.05.2016 | Башкарма комитет җитәкчесе, оешма, предприятие җитәкчеләре. |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | салу) | ел. | |

Югары Ослан муниципаль
районының Макыл авыл
җирлеге башкарма комитеты
җитәкчесенең
2016 ел 26 март № 22
карарына
2 нче кушымта

Макыл авыл җирлеген төзекләндерү комитеты составы

**1.** Цветкова Лилия Рәшит кызы
Макыл авыл җирлеге башкарма комитеты җитәкчесе

**2.** Пичугин Валерий Александрович
9 нчы Сеитово сайлау округы депутаты

**3.** Зиатдинов Ринат Галимҗан улы
2 нче Рус-Макылы сайлау округы депутаты

**4.** Габдрахманов Линар Вилданович
полициянең участок вәкаләтле вәкиле

**5.** Хәкимов Рузалит Тәлгать улы
10 нчы номерлы Клянчино сайлау округы депутаты

**6.** Плохов Виктор Геннадьевич
4 нче Рус-Макылы сайлау округы депутаты